**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 14 апрель № 226

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Башлангыч яки соңгы тукталыш пунктлары Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан спорт ярышлары маршрутлары буенча шәһәр эче һәм шәһәр яны элемтәсендәге автомобиль транспортында (җиңел таксилардан тыш), шәһәр эче элемтәсендәге җир өстендәге электр транспортында, метрополитенда, шулай ук шәһәр яны элемтәсендәге тимер юл транспортында бушлай йөрү хокукын бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 31 гыйнвар, 44 нче карары белән расланган Башлангыч яки соңгы тукталыш пунктлары Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан спорт ярышлары маршрутлары буенча шәһәр эче һәм шәһәр яны элемтәсендәге автомобиль транспортында (җиңел таксилардан тыш), шәһәр эче элемтәсендәге җир өстендәге электр транспортында, метрополитенда, шулай ук шәһәр яны элемтәсендәге тимер юл транспортында бушлай йөрү хокукын бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Башлангыч яки соңгы тукталыш пунктлары Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан спорт ярышлары маршрутлары буенча шәһәр эче һәм шәһәр яны элемтәсендәге автомобиль транспортында (җиңел таксилардан тыш), шәһәр эче элемтәсендәге җир өстендәге электр транспортында, метрополитенда, шулай ук шәһәр яны элемтәсендәге тимер юл транспортында бушлай йөрү хокукын бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 31 гыйнвар, 44 нче карары белән расланган Башлангыч яки соңгы

тукталыш пунктлары Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан спорт ярышлары маршрутлары буенча шәһәр эче һәм шәһәр яны элемтәсендәге автомобиль транспортында (җиңел таксилардан тыш), шәһәр эче элемтәсендәге җир өстендәге электр транспортында, метрополитенда, шулай ук шәһәр яны элемтәсендәге тимер юл транспортында бушлай йөрү хокукын бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге Тәртиптә файдаланыла торган төшенчәләр «Россия Федерациясендә 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионатын, 2017 елгы FIFA Конфедерацияләр кубогын әзерләү һәм үткәрү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 ел, 7 июнь, ФЗ-108 нче Федераль закондагы мәгънәләрдә кулланыла.»;

3 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«спорт ярышлары матчлары үткән көндә һәм спорт ярышлары матчлары үткән көннән соң килүче тәүлекнең 00.00 сәг. алып 06.00 сәг. кадәр спорт ярышлары маршрутлары буенча шәһәр яны элемтәсендәге тимер юл транспортында;»;

4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Спорт ярышлары маршрутлары буенча шәһәр эче һәм шәһәр яны элемтәсендәге автомобиль транспортында (җиңел таксилардан тыш), шәһәр эче элемтәсендәге җир өстендәге электр транспортында, метрополитенда, шулай ук шәһәр яны элемтәсендәге тимер юл транспортында бушлай йөрү хокукы түбәндәгеләргә бирелә:

волонтерлар өчен – спорт ярышларының беренче матчына кадәр бер ай алдан башланган һәм спорт ярышларының соңгы матчы беткәннән соң бер айдан соң тәмамланган чорга;

FIFA исемлегенә кертелгән затлар өчен – спорт ярышларының беренче матчына кадәр 20 көн алдан башланган һәм спорт ярышларының соңгы матчы беткәннән соң 10 көннән соң тәмамланган чорга.»;

6 нчы пунктта «спорт ярышлары маршрутлары буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

7 һәм 8 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Спорт ярышлары маршрутлары буенча шәһәр эче һәм шәһәр яны элемтәсендәге автомобиль транспортында (җиңел таксилардан тыш), шәһәр эче элемтәсендәге җир өстендәге электр транспортында, метрополитенда, шулай ук шәһәр яны элемтәсендәге тимер юл транспортында бушлай йөрү хокукы бирү шартлары түбәндәгеләр:

спорт ярышлары тамашачылары өчен – Россия Федерациясе Элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы раслаган тәртип нигезендә рәсмиләштерелгән персональләштерелгән тамашачы картасы һәм матчка керү билеты яки билет күрсәткән көндә Казан шәһәрендә матчларны үткәрү көнендә стадионга керүне рөхсәт итә торган, FIFA раслаган спорт ярышларының билет сәясәте нигезендә сатып алынган, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән форма буенча матчка керү билетын алуга хокук бирә торган документ (алга таба – билет);

волонтерлар һәм FIFA исемлегенә кертелгән затлар өчен – «Россия-2018» оештыру комитеты» автоном коммерциягә карамаган оешмасы раслаган аккредитация буенча нигезләмә нигезендә рәсмиләштерелгән аккредитация картасы һәм «Россия-2018» оештыру комитеты» автоном коммерциягә карамаган оешмасы белән килештереп рәсмиләштерелгән Казан шәһәренең транспортта йөрү өчен электрон билеты.

Казан шәһәренең транспортта йөрү өчен электрон билеты – әлеге Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән затлар өчен һәм вакыт аралыгында Казан шәһәренең шәһәр эче элемтәсендәге пассажирлар транспортында йөргән өчен түләү буенча автоматлаштырылган системадан файдаланып, гомуми файдаланудагы шәһәр эче элемтәсендәге пассажирлар транспортында йөргән өчен турыдан-туры акча түләмичә операцияләр башкару өчен каралган микропроцессорлы контактсыз смарт-карта. Казан шәһәренең транспортта йөрү өчен электрон билетларын бирү Казан шәһәренең FIFA аккредитация үзәгендә гамәлгә ашырыла.

Күрсәтелгән документларның берсе дә булмаса, бушлай йөрү хокукы бирелми.

Юлда йөрү өчен түләүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыручы затка карап тикшерү яки Казан шәһәренең транспортта йөрү өчен электрон билетын махсус җайланмалар белән тикшерү өчен кирәкле документларны күрсәткәндә генә транспорт чарасына утыруга рөхсәт бирелә.

Юлда йөрү өчен түләүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыручы затлар спорт ярышлары тамашачылары, волонтерлар һәм FIFA исемлегенә кертелгән затлардан юлда йөргән өчен түләүне таләп итәргә яисә, әлеге пунктта күрсәтелгән бушлай йөрү хокукы бирә торган документлар булмаган очракта, юлда йөртү хезмәте күрсәтүне туктатырга хокуклы.

8. Спорт ярышлары тамашачыларына, волонтерларга һәм FIFA исемлегенә кертелгән затларга спорт ярышлары маршрутлары буенча автомобиль транспортында (җиңел таксилардан тыш), шәһәр эче элемтәсендәге җир өстендәге электр транспортында, метрополитенда, шулай ук шәһәр яны элемтәсендәге тимер юл транспортында транспорт хезмәте күрсәтү «Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өстендәге электр транспорты уставы» 2007 елның 8 ноябрендәге ФЗ-259 нчы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өстендәге электр транспорты белән пассажирлар һәм багаж йөртү кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 14 февраль, 112 нче карары һәм Казан шәһәр Думасының «Казан шәһәре метрополитеныннан файдалану кагыйдәләре турында» 2009 елның 11 июнендәге 10-41 номерлы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин